КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 21 март г.Казань № 198

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибе турында» 2016 ел, 17 март, 148 нче карары белән расланган Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибе турында» 2016 ел, 17 март, 148 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 30 апрель, 271 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1061 нче; 2017 ел, 24 апрель, 244 нче; 2017 ел, 22 сентябрь, 708 нче; 2018 ел, 26 апрель, 295 нче; 2018 ел, 19 сентябрь, 799 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бу Тәртиптә кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүләрне гамәлгә ашыру һәм төбәк маршрут челтәрен формалаштыру өчен федераль бюджеттан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү турында» 2013 ел, 25 декабрь, 1242 нче карарында кулланыла торган мәгънәдә кулланыла.»;

3 нче пунктта «гамәлгә ашыру өчен авиапассажирлар йөртүчеләр чыгымнарының бер өлешен» сүзләрен «гамәлгә ашырудан алынып бетмәгән керемнәрне авиапассажирлар йөртүчеләргә» сүзләренә алыштырырга;

6 нчы пунктта:

икенче абзацта «һава транспорты белән йөртүләрне» сүзләре алдына «, авиапассажирлар йөртүчеләрнең эксплуатант сертификатына кертелгән һава судноларыннан файдаланып,» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль һава транспорты агентлыгы белән бу Тәртипкә теркәлгән исемлек нигезендә субсидияләнә торган маршрутлар буенча Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүләрне гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү турында шартнамә төзегән.»;

10 нчы пунктның икенче абзацында «килешү» сүзен «шартнамә» сүзенә алыштырырга;

бу Тәртипкә теркәлгән кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Бу карарның гамәле 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 21 март, 198 нче
карары редакциясендә)

2019 елга Россия Федерациясе территориясеннән һәм (яки) территориясендә гамәлгә ашырыла торган һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең субсидия бирелә торган маршрутлары
исемлеге

| Т/с | Һава транспорты белән йөртү маршрутлары | | 1 атнага парлы рейслар ешлыгы | 1 елга парлы рейслар саны | Махсус тарифның иң чик зурлыгы, сум | 1 парлы рейс өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан авиапассажирлар йөртүчеләргә бирелә торган субсидия күләме, сум * | Һава транспорты белән йөртүләрне башкару чоры |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Шәһәр | Шәһәр | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | Казан | Пермь | 5 | 156 | 3 225,0 | 72 839,49 | 02.01.2019-31.12.2019 |
| 2. | Казан | Түбән Новгород | 4 | 204 | 2 741,0 | 61 691,13 | 02.01.2019 – 31.12.2019 |
| 3. | Казан | Самара | 3 | 89 | 2 258,0 | 50 543,38 | 02.01.2019 – 31.12.2019 |
| 4. | Казан | Оренбург | 5 | 156 | 3 708,0 | 45 269,93 | 01.01.2019 – 31.12.2019 |
| 5. | Казан | Нижневартовск | 2 | 78 | 5 640,0 | 366 125,0 | 02.01.2019 – 31.12.2019 |
| 6. | Казан | Сургут | 2 | 78 | 5 640,0 | 366 125,0 | 02.01.2019 – 31.12.2019 |
| 7. | Казан | Яңа Уренгой | 2 | 78 | 5 640,0 | 366 125,0 | 02.01.2019 – 31.12.2019 |
| 8. | Казан | Омск | 2 | 104 | 5 640,0 | 223 336,25 | 02.01.2019 – 31.12.2019 |
| 9. | Казан | Калининград | 2 | 78 | 5 640,0 | 366 125,0 | 02.01.2019 – 31.12.2019 |
| 10. | Казан | Барнаул | 2 | 104 | 5 640,0 | 223 336,25 | 02.01.2019 – 31.12.2019 |
| 11. | Казан | Махачкала | 2 | 104 | 5 640,0 | 223 336,25 | 02.01.2019 – 31.12.2019 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 12. | Казан | Челябинск | 2 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 13. | Түбән Кама | Ростов-на-Дону | 2 | 76 | 4 674,0 | 106 282,74 | 02.01.2019 – 31.12.2019 |
| 14. | Бөгелмә | Нижневартовск | 3 | 104 | 5 640,0 | 378 503,78 | 01.01.2019 – 31.12.2019 |
| 15. | Бөгелмә | Сургут | 3 | 78 | 5 640,0 | 366 125,0 | 02.01.2019 – 31.12.2019 |
| 16. | Бөгелмә | Яңа Уренгой | 3 | 78 | 5 640,0 | 366 125,0 | 02.01.2019 – 31.12.2019 |
| 17. | Бөгелмә | Ноябрьск | 3 | 103 | 5 640,0 | 366 125,0 | 02.01.2019 – 31.12.2019 |
| 18. | Бөгелмә | Усинск | 3 | 53 | 5 640,0 | 366 125,0 | 02.01.2019 – 31.12.2019 |

*Казан – Яңа Уренгой, Бөгелмә – Яңа Уренгой, Бөгелмә – Ноябрьск маршрутларына мөнәсәбәттә территориянең ераклыгын һәм аңа авыр барып җитүне исәпкә ала торган 1,25 коэффициенты кулланыла.